СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2021 г.Лениногорск № 69

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законнын 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 48, 49 статьялары нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының 2014 елның 19 декабрендәге 60 номерлы карары (2016 елның 27 декабрендәге 110 номерлы, 2019 елның 15 октябрендәге 48 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

2.Конкурс комиссиясенә:

- «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына дәгъва кылучылардан документлар кабул итүне 2021 елның 26 ноябреннән 2021 елның 15 декабренә кадәр Лениногорск шәһәре, Кутузов урамы, 1 нче йорт, 15 нче кабинет адресы буенча, шимбә, якшәмбедән һәм бәйрәм ялларыннан тыш, һәр көнне 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр алып барырга. Белешмәләр өчен телефон: (85555) 5-02-14, факс (855595) 5-16-42.

- конкурсны 2022 елның 23 гыйнварына кадәр үткәргә.

3. Әлеге карарны һәм контракт проектын Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Норматив документлар» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Конкурс турында белдерүне «Лениногорские вести» газетасында бастырырга.

«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы С.В.Тимаков